Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Габдрахман авыл җирлеге башлыгы

# КАРАРЫ

05 ноябрь 2019 ел N 3

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Габдрахман авыл җирлеге Габдрахман авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 нчы статьялары, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Әлмәт муниципаль районы Габдрахман авыл җирлеге Уставының 13.1 статьясы нигезендә,

КАРАР БИРӘ:

1. 2019 елның 20 ноябрендә 18 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Габдрахман авыл җирлегенең Габдрахман авылында Совет урамының № 1-47 нче йортка кадәр, М.Гафури, Һ.Такташ, Октябрь урамының № 45-85 нче йортка кадәр үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенының беренче этабын билгеләргә.
2. 2019 елның 21 ноябрендә 18 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Габдрахман авыл җирлегенең Габдрахман авылында 8 Март, Инеш, Яшьләр,Октябрь урамының № 1-44 нче йортка кадәр, Совет урамының № 2-46 нчы йортка кадәр үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенының икенче этабын билгеләргә.
3. 2019 елның 22 ноябрендә 18 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Габдрахман авыл җирлегенең Габдрахман авылында Г.Тукай, Бакча, Зәй, А.Таһиров, Совет урамының № 51-119 нче йортка кадәр урамнарында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенының өченче этабын билгеләргә.
4. 2019 елның 23 ноябрендә 18 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Габдрахман авыл җирлегенең Габдрахман авылында Нефтяниклар, М.Җәлил, Т.Ислам, Совет урамының № 48 дән - 118 нче йорт, кв. 1 гә кадәр үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенының дүртенче этабын билгеләргә.
5. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2020 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Габдрахман авыл җирлегенең Габдрахман авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 400 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм әлеге средстволарны җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрү белән килешәсезме: Габдрахман авылында асфальт – бетон юлларны ремонтлау, сметалар төзү һәм техник күзәтчелек үткәрү өчен түләү?»

«РИЗА» «КАРШЫ»

6. Халык җыены этапларын Габдрахман авыл мәдәният йорты бинасында, түбәндәге адрес буенча: Татарстан Республикасы Әлмәт районы, Габдрахман авылы, Совет урамы, 75 нче йортта уздырырга.

7. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Габдрахман авыл җирлегенең Габдрахман авылында сайлау хокукына ия булган авыл халкының исемлеген территориаль билге буенча бүләргә.

8. Халык җыенын оештыручы итеп Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Габдрахман авыл башкарма комитетын билгеләргә.

9. Әлеге карарны җыен үткәрү көненә кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча, Габдрахман авылы территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU), Әлмәт муниципаль районы сайтының «Интернет» челтәрендә урнаштырырга (халыкка җиткерергә).

10. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка җиткергән) көненнән үз көченә керә.

Габдрахман
авыл җирлеге башлыгы                                        Р.Ш. Мотаһиров